**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 26 ноябрендәге 4153 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2006 елның 6 маендагы 879 номерлы «Казан шәһәре Думасының 2006 елның 17 февралендәге 12-6 номерлы “Муниципаль предприятиеләрне һәм учреждениеләрне төзү, үзгәртеп оештыру һәм бетерү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында”гы карары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Хезмәт ихтыяҗына бәйле рәвештә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2006 елның 6 маендагы 879 номерлы «Казан шәһәре Думасының 2006 елның 17 февралендәге 12-6 номерлы “Муниципаль предприятиеләрне һәм учреждениеләрне төзү, үзгәртеп оештыру һәм бетерү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында”гы карары турында»гы карары (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2009 елның 5 октябрендәге 8329, 2010 елның 10 сентябрендәге 8132, 2010 елның 31 декабрендәге 11809, 2014 елның 5 августындагы 4639, 2015 елның 19 ноябрендәге 4023, 2016 елның 5 октябрендәге 4049, 2017 елның 17 июлендәге 2662, 2017 елның 13 октябрендәге 4083, 2018 елның 9 августындагы 4427, 2018 елның 20 августындагы 4606, 2021 елның 1 февралендәге 224, 2021 елның 29 мартындагы 741, 2021 елның 20 декабрендәге 3420, 2022 елның 10 мартындагы 692 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган «Казан шәһәренең муниципаль учреждениеләре һәм муниципаль унитар предприятиеләре җитәкчеләрен һәм белгечләрен билгеләү регламентына, икенче, өченче һәм дүртенче абзацларга «“Шәһәрне үстерү институты” муниципаль бюджет учреждениесе» сүзләреннән соң «, Казан шәһәренең туризмны үстерү комитеты” муниципаль казна учреждениесе» сүзләрен өстәп, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче вазифаларын**
**башкаручы – урынбасар** **В.В.Куляжев**